# Иртянге, кичке иманнар (кряшенчя)

По благословению
Высокопреосвященнейшего Анастасия
Архиепископа Казанского
и Татарстанского

К 5-летию (2006-2011) кряшенского прихода
Свт. Николая Чудотворца д. Кряш-Серда
Пестречинского района РТ.
© Кряшенская духовная миссия



# ИРТЯНГЕ ТЕЛЯК

*Урыннан жалкауланмыйчы тороб ӱзеңне рятлягяч, изге тяреляр карышына килеб, эч кюңелеңнян äйт:*

**А**танын, Улнын, Святый Тыннын исеменя. Аминь.

**Э**й Алла, мин жазыклыга изгелекле бул.

**Э**й Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синең кадерле Таза Анаңнын да, кюңелляреңдя Алланы жӧрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар äӱлеяляреңнен дя телякляре какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

Шӧкӧр Сиӈа, эй̆ Аллабыз, шӧкӧр Сиӈа.

Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюӈелгя чын белем Биреӱче Тын, кай̆да булса да бар Син, барын да ӧлгӧрттӧрясен, ӓр-тӧрлӧ жакшылыкка бай̆ Син, терелек Биреӱче Син Ӱзеӈ, безгя килеб урыннаш, безнен ӓр-бер шакшыларыбызны ӓрче, жаннарыбызны коткар, Син изгелекле.

Святый̆ Алла, Святый̆ Кодрятле, Святый̆ Ӱлемсез, безне жарлыка.(3 рят)

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый̆ Тынга, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй̆ иӈ Святый̆ Ӧч ипостасьле Алла, безне жарлыка, эй̆ Ходай̆, безне жазыктан тазарт:эй̆ безне тотоб Тороучы, законыӈнан жазганыбызны кичер: эй̆ Святый̆, безгя изгелек кылыб, безнен житешмягян жиребезне тӧзят, Ӱз исемеӈ ӧчӧн.

Эй Ходай, жарлыка. (*3 рят*)

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга, әле дя, әр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй Кюктяге Атабыз! Данны булыб торсон исемең Синең, килсен Падшалыгың Синең, жирдя дя Кюктягечя булсын иркең Синең, бөгөн көннөк икмягебезне бир безгя, бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк, безне алданырга ирек жибярмя, жаманнан коткар безне.

Эй изгелекле, жокодан торгач Сиңа жыгылыб башырабыз, Син кыуатлыга пяриштяляр жырыуын жырлаб әйтябез: Святъ, Святъ, Святъ Син, эй Алла, Алланы тыудырганнын какына безне жарлыка.

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга .

Эй Ходай, Син мине жокога жаткан урнымнан торгоздон, инде минем уйымны, кюңелемне жактырт, эй Святый Өчлө, Сине

даннаб жырларга ауызымны ачылдыр: Святъ, Святъ, Святъ Син, эй Алла, Алланы тыудырганнын какына безне жарлыка.

Äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Тикшереӳче сизмястян килер, äр кемнең эшляре кюренеб торор, äммя тӧн уртасында тороб куркыныч белян Сиңа дяшеб äйтябез: Святъ, Святъ, Святъ Син, эй Алла, Алланы тыудырганнын какына безне жарлыка.

Эй Ходай, жарлыка. (*12 рят*)

Эй Святый Ӧчлӧ, Син кюб изгелегеңнян, озак тюземнегеннян мин жалкау, жазыклыга ачыуланмаганың ӧчӧн, мине жазыкларыма кюря жугалтмаганың ӧчӧн, äммя гäдятенчя рахим итеб мин ышангычсыз жатканны Ӳз ололоғоңны даннарга торгозганың ӧчӧн, жокодан торгач Сиңа тау итямен. Äле дя минем кюңел кюзляремне жактырт. Ауызым-

ны ачылдыр, Синең сюзляреңя ӧйрянеб, бойорокларыңны аңнасам ыйы, Синең иркеңне кылыб, эч кюңелемнян айтеб Син Атаны, Улны, Святый Тынны жырлаб даннасам ыйы, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Килегез, Падшабыз Аллага башырыйык.

Килегез, Падша Аллабыз Христоска жыгылыб башырыйык.

Килегез, Падша Аллабыз Христосның Ӱзеня жыгылыб башырыйык.

## 50-нче псаломъ.

Эй Алла, Ӱзеңнен оло изгелегеңнян мине жарлыка, Ӱзеңнен кюб рахимеңнян жазыгымны ӓрчеб бетер. Бигряк мине законсызланыуымнан жыу, жазыгымнан мине тазарт. Законсызланганымны тоямын, жазыгым жалан кюз алдымда тора. Мин Синең Ӱзеңюк жазыкландым, жаман эшне кюз алдында

кылдым. Син Ӱз сюзендя туры, хокӧмӧндя мине тейешлечя айыбларсын. Мин анамда жаралгандук жазыклы, анам мине жазыклы кӧйӧ тыудырган шул. Син чынны жаратасын шул, белемнегенгнен айырмачык тӧгӧл жяшереннярен минга белдерттен. Минга сиб-кеч белян сибярсен, мин тазарырмын; мине жыуарсын: мин кардан да бигряк агарырмын. Минга сӧйӧнӧч, кыуаныч эшеттерерсен, уалган сӧяклярем сӧйӧнӧрляр. Жазыкларымнан жӧзӧнгнӧ бор, законсызланыуларымны кичереб бетер. Эй Алла, мине таза кюнгелле ит, эчемдяге тынымны жангартыб, арыу ит. Ӱз жӧзӧнгнян мине кыума, Ӱзенгнен Арыу Тынынгны миннян алма. Коткарыуынг белян мине тагы сӧйӧндӧр, кодрятле Тынынг белян мине ныкландыр. Законсызларны жулларынга ӧйрятермен, бозок кешеляр Синга кайтырлар. Эй Алла, мине саклаучы Алла, кан тюгеӱдян мине коткар, телем Синенг дӧрӧслӧгӧнгне сӧйӧнӧб айтер. Эй Ходай, телемне ачылдыр, ауызым Синенг данынгны айтер. Корман

телясян, китерер эйем, тик Син корман жандырыуны телямейсен. Аллага корман кайгылы тын, Алла кайгылы, жыуаш кюнелне кимсетмяс. Эй Ходай, Ӱз изгелегеннян Сіон тауына жакшылык ит, Іерусалимнен коймалары торгозолсоннар ыйы. Аннары Син дӧрӧслӧк корманын, бюляк кютяреӱне, корман жандырыуны кабыл итярсен, аннары корман урныга бызаулар салырлар.

## Дӧрӧс деннен Символы.

Ышанамын Бер Алла Атага, булган нястялярне тотоучы диб. Кюкне, жирне, кюреня торганны, кюренмей торганны, барысын да Ул булдырган диб. (Жяня ышанамын) Бер Ходай Іисусъ Христоска, Алланын Жангыз тыуган Улы диб, булган багытлардан элеке Атадан Тыуган, жактыдан чыккан жактыдый, чын Алладан Тыуган чын Алла диб; Тыуган, жаратылган тӧгӧл, Ӱзе Ата белян бер, барын да Ул булдырган диб. Без кешеляр ӧчӧн, без-

не коткарыр ӧчӧн, Кюктян иҥеб, Святый Тын кыуаты белян Марія Кыздан тянняneб кеше булган диб. Понтій Пилатъ багытында безнен ӧчӧн Качка кадакланыб, азабланыб, ӱлеб кюмелгян диб. Ӧчӧнчӧ кӧнӧндя ӱлгян жиреннян Алла князясендягечя Терелеб торган диб. Кюккя кютярелеб, Атанын уҥ жагыннан утырган диб. Терелярне, ӱлгяннярне тикшереб айырырга ололок белян тагын килясе, Падшалыгы ич-тя бетясе тӧгӧл диб. (Жяня ышанамын) Святый Тынга, Тере итеӱче Ходай диб, Атадан чыга диб, Ата белян, Ул белян тиҥ табыныулы, тиҥ даннаулы диб, пагямбярляр арткылы Ул сӧйлягян диб. (Ышанамын) Церковька, Апостоллар арткылы бӧтӧн жиргя куйылган бер гня Арыу Жыйын диб. Чумылдырыу бер диб, жазыкларны кичертя диб айтямен. Ӱлгянняр терелеб торасы диб. Мянге тормош буласы диб кӧтямен. Аминь.

## 1-нче иман, изге оло Макарійныкы.

Эй Алла, мин жазыклыны тазарт, мин бер чакта да Синең алдында арыу эш кылмадым шул, мине жаманнан коткар, Синең иркең миндя булсын ыйы, мин ўземнен тейешсез ауызымны айыбламыйчы ачыб, Синең арыу исемеңне, Атаны, Улны, Святый Тынны жырлаб даннасам ыйы, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 2-нче иман, шул ук изгенеке.

Эй Коткарыучы, жокодан уяныб Сиңа тӧн уртасында жырыу китереб, тезлянеб тороб Сиңа инялямен: мине жазыклы кӧйӧ ўлемгя бирмя, мине кызган. Эй Ўз иркеңнян кадаклаunion ныучы, мин жалкауланыб жатыучыны тизряк торгоз, теляктя торган чакта мине сакла. Эй Алла Христосъ, тӧн жокосоннан суң миңа кӧннӧ жазыксыз ўткяздереб, мине коткар.

## 3-нчӧ иман, шул ук изгенеке.

Эй Кеше сӧйӧӱче Алла, жокодан торгач, Сиңа сыйынамын, Ӱз изгелегең белян Синең эшляреңне тырышыб Синнян телеймен. Ӓр-бер чакта, ӓр-тӧрлӧ эшкя миңа кыуат бир, дӧньядя ней усал нястя бар, барысыннан да мине коткар, шайтаннын аздырыуыннан сакла. Мянге Падшалыгыңа кергез, Син Ӱзең мине жараткан, бар жакшылыкларны булдырыб биреӱче Син Ӱзең: минем ышанганым Син Ӱзең. Сиңа дан китерямен, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 4-нче иман, шул ук изгенеке.

Эй Ходай, Син кюб изгелегеңнян, оло рахимнегеңнян бу ӱткян тӧннӧн багытын мин мяндяңя хатярсез, ич-бер зыянсыз ӱткязергя булыштың, инде эй ӓр-нейне Булдырыучы, Башкарыучы Ходай, Ӱзеңнен чын жактыңнан жактырылган кюңел белян Синең иркеңне

кыларга мине Ӱзен тейешле ит, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 5-нче иман, шул ук изгенеке.

Эй Булганны тотоучы Алла Ходай, Син Кюктяге чиреӳлярнен иң арыу жырыуын кабыл итясең, мин тейешсез мяндяңнен дя шушы тӧндяге жырыуын кабыл ал, мин гумеремнен бар жылларында да сагят сайын Син Атага, Улга, Святый Тынга дан китерсям эйе, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь

## 6-нчы иман, изге Василій Великійнеке.

Эй Бар нястяне тотоучы, пяриштялярнен дя, кешелярнен дя Алласы, жугарыда тороб тюбяндягелyргя кюз салыучы, кешелярнен эчлярен, Кюңеллярен кюреӳче, жяшереннярен дя айырмачык белеӳче: Була башлаган чагы жук, Ӱлемсез Падша кимемейчян жалан жалтыраб тора торган Жакты Ходай, безнен

ӓле Синең кюб изгелегеңя ӧмӧтлянеб, кыйы-уланыб, жирянтеч ауызыбыздан иняля торган телягебезне кабыл ал. Безнен эш белян дя, сюз белян дя, уй белян дя, белгян кӧйӧнче, белмягян кӧйӧнче кылган жазыкларыбызны кичер: тянебезне дя, тыныбызны да ӓр-тӧрлӧ шакшылыгыннан ӓрче, бу тормошнын тӧн кюк карангы багытын уяу кюңел белян, сак уй белян ӱткязергя безгя кыуат бир. Без Жангыз тыуган Улың Ходай Аллабыз Ісусъ Христоснын ачык жактырылыб ололок белян килеб бар кешеляргя дя кылган эшляреня тейешлесен кайтарыйым диб тикшерергя килясе кӧнӧн сагайыб торсак ыйы, иренмейче, жалкауланмыйчы, уяу эшляб торган кӧйӧнче Аңар очораб, Аның зур сӧйӧнӧчлӧ жомагына керсяк эйе, андагыларнын сӧйӧнӧч ауазлары тукталмый, анда Синең жӧзӧңнӧн ӓйтя алырлык тӧгӧл ӓйбятлеген кюреб сӧйӧнӧуляреҥ ӓйтеб житкезер хал жук, Булганнарны жактыртыучы чын Жакты Син, ӓр нястяляр дя Сине гумердян гумергя ололаб данныйлар. Аминь.

## 7-нче иман, шул ук изгенеке.

Эй Жугарыдагы Алла, эй рахимне Ходай, без уйлаб белеб житкезя алмаслык ис китяр-лек кюб изгелекляренгне кылганың ӧчӧн, эш-ляб торган тянебезне тынычландырыб, хале-безне жыярга жоко биргянең ӧчӧн Сине дан-ныйбыз. Син безне жазыкларыбызга кюря жугалтмаганың ӧчӧн гядятеңчя рахим итеб, ышангычсыз жатканны Ӱз олологолңны дан-нарга торгозганың ӧчӧн Сиңа тау итябез. Ан-нары тагы Синең чамасыз изгелегеңя иня-лябез: уйыбызны, кюзебезне ачылдыр, кюңелебезне жалкаулык жокосоннан уят, ау-ызыбызны ачылдырыб, Ӱзеңне даннат. Бул-ганнар яр-турда ололой торган Син Алланы, Була башлаган чагы жук Атаны, Жангыз ты-уган Улыңны, Терелек итеӱче, изгелекле Свя-тый Тыныңны жалан жырлаб данный алсак ыйы, яле дя, яр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 8-нче иман, Алла Анасына.

Эй Башкарыучы Кыз, Синең дяўлятеңне жырлаб Сиңа инялямен, минем уйымны дяўляткя тулыландырыб Христоснын бойорокларынын жулыннан бастырыб, алардан дӧрӧс барыучы ит, моңайыулык жокосон кыуыб, уяу тороб Алланы даннарга ныгайт. Мин жазыкка жыгылыу бяйлеге белян бяйлянгянне, эй Аллага жяряшелгян Кыз, Ўз теляклярең белян чиш. Минем белян жиңешя торган дошманнардан коткарыб, кӧндӧз дя, тӧння дя мине сакла. Син Терелек биреўче Алланы тыудырыучы, мине няпесляр белян ўтерелгянне терелт. Оло Жактыны Тыудырыучы, минем сукырайган жанымны жактырылдыр. Эй Башкарыучы Ходайнын ис китярлек Жорто, мине Алла Тыны торорлок жорт ит. Син Тӧзятеўчене Тыудырыучы, минем жанымнын кюб жылгы чирлярен тӧзят. Мин тормош тулкынында жӧрӧўчене тяўбя сукмагына ынгайла. Мине мянге уттан, жаман корттан, тартар дигян урыннан да котка-

ра кюр. Мин кюб жазыклар белян айыблыны женняргя сӧйӧнӧч итеб кюрсятмя. Эй шиксез Кыз, мин тоймаслык жазыклар белян искергянне жанa кеше ит. Барын да Башкарыучы Ходайга инялеб ӓр-тӧрлӧ азабтан мине чиття тот. Эй иң Изге Кыз, бар изгеляр белян бергя Кюктяге сӧйӧнӧчнӧ алырга мине тейешле ит. Мин жараусыз мяндягнен ауазын эшет. Жанымнын шакшысын тазартырга кюз жяшляремне кюб итеб агыз: кюнгелем белян сызланыб Сиңа теляк китерямен. Эй Башкарыучы Кыз, Син дя жалан минем ӧчӧн сагышлансаң ыйы. Минем шушы теляк хызмятемне кабыл алыб, Арыу кюнгелле Аллага китер, Син пяриштялярдян дя жугары, мине дӧньянен буш нястяляреннян жугары ит. Кюктяге Жактыны жӧртӧуче, миндя тын дяулятен арттыр. Мин шакшыланган кулларымны кютяреб, ауызымны ачыб Сине мактыйым, Христоска тырышыб инялеб, жанны черетя торган шакшылардан коткар. Аңар кадерляб табыныу тейешле, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь

## 9-нчы иман, безнен Аллабыз Іисусъ Христоска.

Эй Кюб изгелекле, Кюб рахимне Алла Ходайым Іисусъ Христосъ, Ӱзенгнен ӓдям затын сӧйӧӱлӧгӧнг какына, бар кешелярне дя коткарыйым диб жирдя Син кеше булыб Тыуган. Шунгар кюря мин дя Синга инялямен, эй Коткарыучым, мине дя коткарсанг ыйы. Ӓгяр мине эшляремя караб кна коткарсанг, ул изгелек дяӱляте тӧгӧл, кылган эшкя тейешлене кайтарыулык кна. Шунгар кюря, эй Кюб изгелекле, ӓйтеб бетермяслек жумарт Христосым, Син ӓйткяненг: “Минга ышаныучы тере торор, ул ӱлмяс гумергя” дигяненг. Ӓгяр шулай Синга ышаныулык мин ӧмӧтсӧзнӧ дя коткара торган булса, Синга ышанамын, Син мине Коткарыучы Алла Ӱзенг бул, минем ышаныуым арыу эшляр урнына саналсын ыйы. Инде эй Аллам, миннян ӱземне дӧрӧскя чыгарырлык эшляр сорой кюрмя, ӓммя минем шул ышаныуым бар жакшы эшлярем урнына булсын ыйы, ул минга дӧрӧскя чыгарга, мянге

тормошка,ышанычлы жауабка булсын ыйы, Синең мянге сӧйӧнӧчлӧ жомагыңа алыб барсын ыйы. Эй Сюз Алла, Синең кулыңнан, кӧйманң эченнян шайтан алыб китеб, аны ӱз кулыма алдым диб мактанмасын ыйы. Эй Коткарыучым Христосъ, инде телясям дя, телямясям дя, мине Ӱзең коткара кюр. Мин харяб булгынчы тиздян-тиздян коткар, жугыйса мин харяб булырмын. Анам эченнянюк Син минем Аллам. Эй Ходай, бӧгӧнгя чаклы шул жазык эшлярен сӧйгян кюк, мыннан былай инде Сине сӧяргя миңа Ӱзең булыш, элеке алдаучы шайтанга хызмят иткян кюк, мыннан былай Сиңа жалкауланмыйчы хызмят итяргя тейешле ит. Син Ходай Аллам Іисусъ Христоска гумеремнен бар кӧннярендя дя бигряк тырышыб хызмят итсям эйе, äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 10-нчы иман, саклаучы Пяриштягя.

Эй изге Пяриштя, Син минем мескен жанымны, няпесле тормошомны саклаб тороу-

чы, мин жазыклыны ташлама, тыйнаксызлыгыма караб миннян бизмя, минем ӱлярлек тянемне усал дошманга биляб торорга ирек жибярмя. Халсез начар кулларымны ныкландырыб мине котолоу жулына бастыр, эй Алланын мескен жанымны да, тянемне дя саклаб тороучы изге Пяриштясе, бар торган кӧнняремдя дя ней белян гня катеренгне калдырган булсам да, бу ӱткян тӧннӧ жазыкланган булсам да, барысын да минга кичер, бӧгӧнгӧ кӧннӧ мине жаклаб, жаман алданыудан мине сакла, ичбер жазык белян дя Алламнын катерен калдырмасам ыйы. Минем ӧчӧн Ходайдан теля, Ӱзенгнян куркырга минга уй бирсен, Ӱзенен изгелегеня мине дя тейешле итсен эйе. Аминь.

## 11-нче иман, Алла Анасына.

Эй Алланы тыудырган мине Башкарыучы ин Изге Кыз, Ӱзенгнен кыуатлы изге теляклярен белян мин жыуаш, мескен мяндянгнян ӧмӧтсӧзлӧкнӧ,онотолоулыкны,

акылсызлыкны, жалкаулыкны, ӓр-тӧрлӧ жаман, шакшы, курлык уйларны минем жазыкланган кюнгелемнян, карангыланган уйымнан кыуыб жибяр, минем няпеслярем-нен жалкынын сюрелдер, мин жарлы, мескен шул, мине кюб усал уйларымнан, тоткан исябляремнян коткар, ӓр-тӧрлӧ жаман эшлярдян мине иркенгя чыгар. Сине бар затлар да даныйлар, Синенг инг кадерле исеменгне гумердян гумергя мактыйлар. Аминь

## Ӱз ӓӱлеяня.

Эй Алланын ӓӱлеясе (*исеме*), минем ӧчӧн Аллага инял, мин синга сыйыныб чын кюнгелемнян инялямен: сине тиз булышыучы, жаным ӧчӧн теляк итеӱче диб белеб.

## Алла Анасына жырыу.

Алланы тыудырган Кыз, сӧйӧн, дяӱлятенг бар Марія, Ходай Синенг белян. Безнен жан-

нарга Коткарыучыны Тыудыргач, Син данны булган катыннар арасыннан, Синнян Тыуган да даннаулы.

## Качка.

Эй Ходай, калкынгны сакла, жортонга бярякят бир. Дӧрӧс денне ололаб тотоб саклаучыларга дошманнарын жингеб басарга кыуат бир, Качынг белян сакла тоткан тормошонгны.

## Иман, исянняр ӧчӧн.

Эй Ходай, сакла, жарлыка минем духовный атам (*исеме*), мине тыудырган атам-анам (*исемняре*), карендяшляремне (*исемняре*), башлыкларымны, минга жакшылык кылганнарны (*исемняре*), барлык Христосъ денен дӧрӧс тотоучыларны барысын да сакла.

## Ӱлгянняр ӧчӧн.

Эй Ходай, исеня ал ӱлгян мяндяляренгне: минем атам анамны, тыуганнарымны, минга жакшылык кылганнарны (*исемняре*), барлык православный христіаннарны да, ирекле, ирексез кылган жазыкларын кичереб, аларны Ӱзенгнен Кюктяге Падшалыгынга керт.

## Исянняр ӧчӧн.

Эй Ходай Аллабыз Іисусъ Христосъ, Ӱзенгнен мянгедяге изгелекляренгне, жумартлыгынгны исеня ал. Син шунгар кюря кеше булыб тяннянгян дя ич: Синга дӧрӧслӧк белян ышаныучыларны коткарыр ӧчӧн Качка кадакланыб ӱляргя дя риза булган, ӱлгяннегенгнян Терелеб тороб, Кюккя кютярелеб Алла Атанын унг жагыннан утырасын, чын кюнгелляреннян жыуашлык белян Синга инялеӱчелярнен телягеня кюз салыб торасынг. Колагынгны салыб мин жараусыз мяндягнен бар кешеляр ӧчӧн жыуашлык белян итя тор-

ган телягемне эшетеб, арыу эйесле май урнына кабыл ал. Иң элеке Апостоллар аркылы бӧтӧн жиргя куйылган, Ӱзеңнен Таза Каның тора торган Арыу Жыйыныңны ныгайт, кюбяйт, тынычландырыб тамук кабкасы да жиңя алмаслык итеб гумерляр буйына сакла. Жыйыныңны айырылышыудан сакла, денсезлярнен какшатыуын сюндер, жалган ӧйрятеӱляр кютярелеӱен тизюк басылдырыб жолкоб ташла. Ӱзеңнен Арыу Тыныңнын кыуаты белян жукка чыгар. (*Башыр*)

**Э**й Ходай, сакла, жарлыка безнен Алла саклый торган илебезне, анын башлыкларын, чиреӱлярен. Изге тормош белян без дя кайгысыз тыныч торсак ыйы. (*Башыр*)

**Э**й Ходай, сакла, жарлыка жир жӧзӧндяге арыу православный патриархларны, арыу митрополитларны, архиепископларны, епископларны, священниклярне, диаконнарны, бар чиркяӱдя хызмят итеӱчелярне, аларны

Ӱзенгнен сӧйляшя торган кӧтӧӱӧнгне кӧтяргя куйганыӈ, аларнын телякляре какына мин жазыклыны да жарлыкаб коткара кюр. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка минем духовный атам (*исеме*), анын изге телякляре какына минга жазыкларымны кичер. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка картларны, жяшлярне, жарлыларны, ӱксезлярне, тол катыннарны, чирдя, кастярдягелярне, читеннек кюреӱчелярне, кайгылыларны, комачауда, тотконда жабылыуда тороучыларны. Ӓммя бигеряк Синеӈ ӧчӧн, чын ден ӧчӧн, денсез калыклардан, деннян бизеӱчелярдян, денне бозоб ӧйрятеӱчелярдян кысаннык кюреӱче мяндяляреӈне сакла, аларны исеӈя ал, аларга булышлыкка кил, аларны ныгайт, жыуат, Ӱз кыуатыӈ белян тизеннян аларга жиӈеллек, иркеннек, котолоулык бир. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка минем атам-анамны (*исемняре*), туганнарымны, карендяшляремне, ырыу тамырларымны,

таныш-белешляремне, аларга Ӱзенгнен арыу тынычлыгынгны бир, Ӱз бойорокларынгнын жулыннан жӧрт. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка хызмяткя жибярелгяннярне, жулда жӧрӧӱче аталарыбызны, туганнарыбызны, аннары чын денне тотоучы христіаннарнын барысын да сакла. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка мин ӱземнен акылсызлыгым белян алдандырган мяндяляренгне аларны котолоу жулыннан биздереб, начар, тейешсез эш кылдырган булсам, аларны Ӱзенгнен Аллалык белемнегенг белян жанадан котолоу жулына бастыр. (*Башыр*)

Эй Ходай, сакла, жарлыка мине кюрялмый тороучыларны, мине кимсетеӱчелярне, минга начарлык кылыучыларны, мин жазыклы мяндя ӧчӧн аларны харяб булырга калдыра кюрмя. (*Башыр*)

Чын деннян бизеӱчелярне харяб итя торган жангыш ӧйрятеӱляр белян карангылан-

ганнарны, Сине белеўлекнен жактысы белян жактырылдыр, аларны Апостоллар арткылы бӧтӧн жиргя куйылган Арыу Жыйынынга кушылдыр. (*Башыр*)

## Ўлгянняр ӧчӧн.

Эй Ходай, бу тормоштан кючкян арыу православный патриархларны, кадерле митрополитларны, архиепископларны, епископларны, священниклярне, жя чиркяў хызмятендя, монахлык хызмятендя тороб ўлгяннярне, аларнын барысын да Ўзенгнен мянгелек урнынга изгеляр белян бергя тынычландыр. (*Башыр*)

Эй Ходай, ўлгян мяндяляренгнен жаннарын исенгя ал. Минем атам-анамны (*исемняре*), бар карендяшляремне, аларнын иректян, ирексездян кылган бар жазыкларын кичер, аларга Кюк Падшалыгында урын биреб Ўзенгнен мянге жактылыгынга ӧлӧштяш итеб, Ўзенгнен мянге рахят тормошонгнын кыуанычын бир. (*Башыр*)

Эй Ходай, терелеб мянге тормошта булырбыз диб ӧмӧтлянеб ӱлгян аталарыбызны, ага-эне, тута-сеӊеллляребезне, шушында, ӓр-бер жирдя жата торган христіаннарны барысын да исеня ал. Ӱз жӧзӧнгнен жактылыгы жактыра торган урында изгеляре белян бергя урынназштыр. Ӱзен изгелеклегя, кеше сӧйӧӱчегя кюря безне дя жарлыка. Аминь. (*Башыр*)

Эй Ходай, ден тотоб, терелеб торорга ӧмӧт тотоб ӱлгян аталарыбызга, ага-эне, тута-сеӊелляребезгя жазыкларын кичер, аларны мянгегя исендя тот. (*3 рят укыла*)

Чыннаб дӧрӧс тейешле, Эй Алланы тыудырган Кыз, Сине кадерляргя, Син мянгегя кадерле, шиксез Таза, Син безнен Аллабызнын Анасы, Херувимнярдян дя кадерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз кӧйӧ Сюз Алланы тыудырган чын Алла Анасы, Сине ололойбыз.

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй̆ Ходай̆, жарлыка. (*3 рят*)

Эй̆ Ходай̆ым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синен̆ Кадерле Таза Анан̆нын, кюн̆еллярендя Алланы жöрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар ăулеяляренгнен теляклярe какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

## Пасхадан Кюкка кÿтярелеÿгя кадяр «Чыннаб дöрöс тей̆ешле» урнына жырлана торган иманнар.

Пяриштя дяÿлятле Маріяга дяшеб ăй̆ткян: сöй̆öн Таза Кыз диб. Жяня тагын сöй̆öн диб ăй̆тямен, Синен̆ Улын̆ кабердян öчöнчö кöннö Терелеб тордо, ÿлгяннярне дя торгоздо дигян. Эй̆ кешеляр, сöй̆öнöшöб кыуанышый̆ык.

Жактырыл, жактырыл, эй̆ жан̆а Іерусалимъ. Ходай̆нын кодряте Син̆а жактырган, инде Син сöй̆öнöб кыуан, эй̆ Сіонъ. Эй̆ Алланы тыудырган Изге, Арыу, Таза Кыз, Син дя Улын̆нын Терелеб торганына сöй̆öн.

## Пасхадан Фома атнасына кадяр иртянге, кичке теляк урынына укыла торган иманнар.

Христосъ ӱлгяненнян Терелеб торган, ӱлгяннеге белян ӱлемнен кыуатын бетергян, ӱлгян кешеляргя дя терелек биргян. (*3 рят*)

Христоснын Терелеб торганын кюргяч, Святый Ходай, жазыксыз бер Іисуска башырыйык. Эй Христосъ, Синен Качынга башырабыз, Синен Арыу Терелеб тороуынгны да даннаб жырлыйбыз, шунын ӧчӧн Син безнен Аллабыз, Синнян башка бютянне белмейбез, Синен исеменгне данныйбыз. Эй ышаныучылар, барыгыз да килегез, Терелеб торган Святый Христоска башырыйык, мына Кач белян булган дӧньягя сӧйӧнӧч килгян. Ходайны жалан даннаб, Анын Терелеб торганын жырлыйык, кадакланыуга тюзеб, ӱлгяннеге белян ӱлемнен кыуатын бетергян. (*3 рят*)

Иптяшляре белян Маріія тан атмас борон барыб, кабер ауызыннан аударылган ташны

кюргянняр, Пяриштядян дя сюз эшеткянняр: гел жактыда тороучыны ней ӧчӧн кешене эзлягян кюк ӱлекляр арасыннан эзлейсез? Кабер эчендяге кипенен кюрегез: тиз барыб, дӧньядяге кешеляргя сӧйӧнӧч айтегез, Ходай ӱлемнен кыуатын бетереб тордо, Ул Алланын кешелярне Коткарыучы Улы дигян.

**Э**й ӱлемсез Алла Христосъ, Син жир астына тӧшсян дя тамукнын кыуатын бетереб Терелеб торган, эйесле май алыб килеӱче катыннарга сӧйӧнӧгӧз! дигян, Апостолларынгны да тынычландырган, жыгылганнарны да торгозган.

**Э**й Христосъ, Син чиге жук Алла икяннегенгнян тян белян кабердя, жан белян тамукта, талаучы белян жомакта, Ата белян, Святый Тын белян Аллалык урнында, бер чордук ăр тӧштя дя булган.

**Ш**ӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга. Эй Христосъ, Синенг терелек чыгарыучы кабереңг чыннаб жомактан да айбят, ăр-бер падша

гюрнячясеннян дя жакты, Ул безгя терелек агызган.

Äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь. Эй Жугарыгы Ходайнын арыуланган, Алла сайлаган урны, Алланы тыудырыучы, сӧйӧн, Син катыннар арасыннан данны булган, эй Изге Алла Анасы диб äйтеӱчеляргя Синеҥ арткылы сӧйӧнӧч бирелгян.

Эй Ходай, жарлыка. (*40 рят*)

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга, äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Херувимнярдян дя кадерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз кӧйӧ Сюз Алланы тыудырган чын Алла Анасы, Сине ололойбоз.

Христосъ ӱлгяненнян Терелеб торган, ӱлгяннеге белян ӱлемнен кыуатын бетергян, ӱлгян кешеляргя дя терелек биргян. (*3 рят*)



# КИЧКЕ ТЕЛЯК

Атанын, Улнын, Святый Тыннын исеменя. Аминь.

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синең кадерле Таза Анангнын да, кюнгелляренде Алланы жёрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар ăўлеяляренгнен дя теляклярe какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

Шӧкӧр Синга, эй Аллабыз, шӧкӧр Синга.

Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюнгелгя чын белем Биреўче Тын, кайда булса да бар

Син, барын да ӧлгӧрттӧрясен, ӓр-тӧрлӧ жакшылыкка бай Син, терелек Биреӱче Син Ӱзенг, безгя килеб урыннаш, безнен ӓр-бер шакшыларыбызны ӓрче, жаннарыбызны коткар, Син изгелекле.

Святый Алла, Святый Кодрятле, Святый Ӱлемсез, безне жарлыка. (*3 рят*)

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй инг Святый Ӧч ипостасьле Алла, безне жарлыка, эй Ходай, безне жазыктан тазарт, эй безне тотоб Тороучы, законынгнан жазганыбызны кичер, эй Святый, безгя изгелек кылыб безнен житешмягян жиребезне тӧзят, Ӱз исемен ӧчӧн.

Эй Ходай, жарлыка. (*3 рят*)

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый Тынга, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй Кюктяге Атабыз! Данны булыб торсон

исемең Синең, килсен Падшалыгың Синең, жирдя дя Кюктягечя булсын иркең Синең, бӧгӧн кӧннӧк икмягебезне бир безгя, бурычларыбызны кичер, без дя безгя бурычлы булганнарга кичергян кюк, безне алданырга ирек жибярмя, жаманнан коткар безне.

Безне жарлыка, эй̆ Ходай̆, безне жарлыка, без жазыклылар ӱзебезне дӧрӧсляргя бер жауаб та биря алмагач, тик Син безне тотоучыга шушылай̆ гна инялябез: эй̆ Ходай̆, безне жарлыка.

Шӧкӧр Атага, Улга, Святый̆ Тынга.

Эй̆ Ходай̆, безне жарлыка, Сиңа ӧмӧтлянеб торабыз, безгя каты ачыуыңны китермя, законыңнан жазганыбызны исендя тотма, эй̆ изгелекле Ходай̆, äле безгя кюзеңне сал, дошманнарыбыздан безне коткар, безнен Аллабыз Син, без Синең кешелярең, Ӱз кулың белян булдырганнарың Синең исеменя сый̆ынабыз.

Ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Алланы тыудырган изгелекле Марія, изгелек ишеген ач безгя, без Сиңа ышаныб торганнарны жугалттырма, бялялярдян коткар, Син Ӱзеӊ Христоска ышаныучыларны котолдырыучы.

Эй̆ Ходай̆, жарлыка. (*12 рят*)

## 1-нче иман, изге оло Макарійныкы, Алла Атага.

Эй̆ мянге Алла, эй̆ бар булдырылганнарнын Падшасы, мине бу сагяткя житешергя тейешле кюреӱче, бӧгӧн эш белян дя, сюз белян дя, уй̆ белян дя кылган жазыкларымны миңа кичер. Эй̆ Ходай̆, минем мескен жанымны да, тянемне дя, тынымны да ӓр-тӧрлӧ шакшылыгыннан тазарт. Эй̆ Ходай̆, бу тӧннӧ тыныч жоклаб ӱткязергя миңа булыш, мин жарлы гна урнымнан тороб гумеремнен бар кӧнняренд**я**

дя Синеӊ арыу исеменӊне даннасам ыйы. Шулай итеб минӊа карышылык итеӳче тянне, тянсез дошманнарны жингсям эйе. Эй Ходай, мине шакшыландыра торган жаман няпеслярдян, буш уйлардан мине коткар. Эй Ата, Ул, Святый Тын, Падшалык, кыуат, ололок Синеке, äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 2-нче иман, изге Антіохныкы,безнен Ходайыбыз Іисусъ Христоска.

Эй Барын да тотоучы Алла Сюзе, эй иӊ кадерле Іисусъ Христосъ, Ӳзенӊнен кюб изгелегенӊ какына мин мяндянӊне ташлама, äммя жалан минем белян була кюр. Эй Ӳзенӊнен сарыкларынӊны арыу кӧтӧӳче Іисусъ, мине жыланнын усаллыгына ирек бирмя, мине шайтан иркеня калдырма, миндя ӳлем орлого бар шул. Эй без табына торган Алла Ходай, изге Падша Іисусъ Христосъ, Ӳзенӊнен бетмей торган жактынӊ белян ӧйрянеӳчеляренӊне

арыуландырган, Святый Тының белян мине жоклаган чагында сакла. Эй Ходай, жоклаган урнымда мин жараусыз мяндянгя котолоу бир. Минем уйларымны Ӱзеңнен Арыу Евангеліенгне аңнаулык жактысы белян жактырт. Жанымны Качынңны сöйӧӱлӧк белян, кюнгелемне таза, изге сюзлярең белян, тянемне няпеслярне басылдыра торган азабларын белян, уйымны Ӱзеңнен жыуашлыгың белян саклаб, тейешле багытта мине Ӱзеңне даннарга торгоз. Син Була башлаган чагы жук, Атаң белян, иң Изге Арыу Тының белян гумергя даннаулы шул. Аминь.

## 3-нчӧ иман, изгелекле Святый Тынга.

Эй Ходай, Кюк Падшасы, жанга Тынычлык, кюнгелгя чын белем Биреӱче Тын, изгелекле кюнгелең белян мин жазыклы мяндянгне жарлыкаб, мин тейешсез мяндянгя бöгöнгö жазыкларымны барын да ташла, кичер, ӓдям кюк мин бöгöн жазыкландым, ӓдям кюк кня

тӧгӧл, ӓммя терлеклярдян дя начаррак кыйландым, минем иректян, ирексездян, белеб, жя белмей кылган жазыкларым, жяштян начарлыкка кюнекканнектян, оятсызлыктан, ӧмӧтсӧзлӧктян, Синең исемең белян каргангаң булсам, жя кюңелем белян исемеңне курлаган булсам, беряӱне-беряӱне тиргягян булсам, ачыуланыб ӓляклягян булсам, жя кайгырткан булсам, жя бер-бер нястягя ачыуланган булсам, жя алдаган булсам, жя тейешсез багытта жоклаб жаткан булсам, жя минем катка жарлы килеб аны кабыл алмаган булсам, жя туганымны кайгырткан булсам, жя беряӱне айыблаган булсам, жя мактанган булсам, жя олосымакланган булсам, жя ачыуым килеб жарсыган булсам, жя мин теляктя торганда уйым бу дӧньянен начарлыгына ауышкан булса, жя арыулыктан ауышыуны уйлаган булсам, жя артык ашаган булсам, жя артык эчкян булсам, жя тилереб кӧлгян булсам, жя начар эшлярне уйлаб жӧргян булсам, жя кешедя ӓйбят ӓйбер кюреб аңар кюңелемне

салган булсам, жя тейешсез сюз сӧйляшкян булсам, жя туганымнын жазыгыннан кӧлгян булсам, минем шул жазыкларым санаб бетергессез, жя теляк итяргя жалкауланган булсам, жя бютян тагы исемя килмей торган жаман эшлярем булса, алары бу ӓйткянняремнян дя кюбряктер. Шунгар кюря эй мине Булдырыучы, Башкарыучы, мин ӧмӧтсӧз, тейешсез мяндянгне жарлыкаб Ӱзенг Кеше сӧйӧӱче изгегя кюря минга ташла, чиш, кичер. Мин жазыклы, азгын, жараусыз, тынычланыб жоклаб тӧннӧ ӱткярсям эйе. Аннары Синга табыныб инг кадерле исеменгне Ата белян, Анын Жангыз тыуган Улы белян жырлаб даннасам ыйы, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 4-нче иман, изге оло Макарійныкы.

Эй безгя кюб арыулыклар биргян Ӱлемсез Падша, Кеше сӧйӧӱче, жумарт Ходай! Мин Синга ней кайтарыйым, Синга ней китерейем, мин Синга жараулыны кыларга жалкауланыб

ич-тя арыулык кылмаган мяндянгне шушы узган кӧннӧн азагына китереб житкезден. Жанымны тяўбя итеб котолошлы итеб тӧзягянен. Мин жазыклыга, ăр-бер арыу эшкя жалангачка изгелекле бул. Минем чамасыз жазыклар белян шакшыланыб жыгылган жанымны кютяреб торгоз. Бу кюреня торган тормошнын жаман уйларын бӧтӧнняй миннян алыб ташла. Эй бер гня жазыксыз Ходай, минга жазыкларымны кичер, бӧгӧнгӧ кӧннӧ ней белян гня булса да, белеб, жя белмей, сюз белян, эш белян, уй белян, бар тойоноуларым белян жазыкланган булсам да, минга кичер. Син Ўзен мине Аллалык кыуатын белян, айтеб житкезеўсез сойоўлӧгӧн какына, ăр-тӧрлӧ карышыучы нястядян жабыб сакла. Эй Аллам, Ўз кыуатын белян мине тазарт, минем кюб жазыкларымны тазарт. Эй Ходай, мине жаманнын ауыннан котолдороб, минем жанымны коткарыб зур дан белян килгян чагында жӧзӧнгнӧн жактысы белян мине жактыртырга ризалык ит. Хазер дя айыблан-

мыйчы жоклаб китсям эйе. Мин мяндягнен кюнгеленя тӧрлӧ уйлар китермейче, саклаб, шайтаннын ӑр-бер эшлярен миннян кыуыб жибяр. Минем кюнгелемнен акыл кюзлярен жактырылдыр, мин ӳлем жокосо белян жокламасам ыйы, минем жанымны да, тянемне дя сакларга ӧйрятеӳче, тынычландырыучы, саклаучы Пяриштягне жибяр. Ул мине дошманнарымнан аралаб алсын ыйы. Мин урнымнан тороб Синга тау итеӳ теляге китерсям эйе. Эй Ходай, мин жазыклы, ӑр-тӧрлӧ тыйнаклыктан жарлы мяндягне эшет. Мин урнымнан торгач Синег сюзляреня ӧйрянсям эйе. Ӱз пяриштялярег белян жаман тын жибяря торган могайыулыкны жырак кыуыб жибяр. Синег арыу исемегне тау итеб даннасам ыйы. Алланы тыудырган инг Таза Кыз Маріяны да жалан даннасам ыйы, Син Аны без жазыклыларны жаклаучы итеб биргянег. Анын безнен ӧчӧн иткян теляген кабыл ал. Ул да Синег кеше сӧйӧӳлӧгеня ошашлы булыб безнен ӧчӧн теляк итеӳдян тукталма-

ганны мин белямен. Анын жаклауы буйынча, бар изгеляренкакына, эй Аллабыз Іисусъ Христосъ, кадерле Качыгнын билгесе белян изгелеген какына минем жарлы жанымны саклаб тор. Син даннаулы гумергя. Аминь.

## 5-нче иман.

Эй Ходай Аллабыз! Бöгöн эш белян булса да, сюз белян булса да, уй белян булса да кылган жазыкларымны барысын да Син изгелеген какына, ӓдямне сöйöулöген какына минга кичер. Минга рахят, тыныч жоко бир, ӓр-тöрлö усал нястядян жабыб сакларга Пяриштягне жибяр: жаннарыбызны, тянняребезне саклаучы Син Ӱзен. Син Атага, Улга, Святый Тынга дан китерябез, ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 6-нчы иман.

Эй без ышана торган Ходай Аллабыз, без Синен исеменя бютян ӓр-бер исемнян дя би-

гряк сыйынабыз, без жокларга тороучылар-га жаныбызга да, тянебезгя дя тынычлык бир. Ăр-тӧрлӧ жаман, азгын уйлардан безне сакла, безнен тян няпесляребезне басылдыр, безгя эшляребездя дя, сюзляребездя дя шиксез тороргга кыуат бир, без Син безгя бирясе изгелеклярдян буш калмас ӧчӧн арыу эшляр гня кылыб торсак ыйы, Син шул гумергя даннаулы. Аминь.

## 7-нче иман, изге Іоаннъ Златоустныкы (кӧннӧн, тӧннӧн сагятляре санынча, 24 иман)

1. Эй Ходай, Син мине Кюктяге дяўлятенгнян буш калдырма.
2. Эй Ходай, мине мянге азабтан коткар.
3. Эй Ходай, уй белян, жя исяб белян, жя сюз белян, жя эш белян кылган жазыкларымны кичер.
4. Эй Ходай, мине акылга китер, онотол-

дорма, жанымны жӧдяӳгя калдырма, каты кюӈелемне жомошат.

5. Эй̊ Ходай̊, мине ӓр-тӧрлӧ алданыудан сакла.

6. Эй̊ Ходай̊, минем азгынныk карангыландырган кюӈелемне жактырт.

7. Эй̊ Ходай̊, мин жазыклы кеше, Син кызганыучан Алла, Син минем халсезлянгян жанымны кюреб, мине жарлыка.

8. Эй̊ Ходай̊, минга Синеӈ арыу исемеӈне даннатырлык жакшы эшляр кыларга кыуатыӈны биреб булыш.

9. Эй̊ Ходай̊ Іисусъ Христосъ, мин мяндяӈне терелек князясеня жаз: ӳлгяч минга арыу урын бир.

10. Эй̊ Ходай̊ Аллам, минем Синеӈ алдында кылган бер дя жакшы эшем жук, Син минга Ӳз изгелегеӈнян арыу тормош башларга кыуат бир.

11. Әй Ходай, минем кюнгелемне Ӳз изгелегенг белян жомошатыб арыула.
12. Әй Кюкне, жирне булдырган Ходай, мин усал, карангы, жирянгеч мяндягне Падшалыгында исенгя ал. Аминь.

1. Әй Ходай, мин тяӱбягя килеӱчене кабыл ал, жазыкларымны кичер.
2. Әй Ходай, мине ташлама, мингa булыш.
3. Әй Ходай, мине тыгызлыкка туры китермя.
4. Әй Ходай, мингa арыу исяб бир.
5. Әй Ходай, ӱлясемне исемя китереб, кюнгелемне жомошатыб мине жылат.
6. Әй Ходай, жазыкларымнан кайтырга мингa сагыш бир.
7. Әй Ходай, мине жыуашландыр, кюнгелемне тазарт, кушкан сюзне

тыңнаучан ит.

8. Эй Ходай, мине тюземне ит, чыдам жанны ит, сабырлыклы ит.

9. Эй Ходай, Синнян куркыудан ӓр тӧрлӧ арыу эшляр буладыр, айса Син Ӱзеңнян мине Ӱзең куркыт.

10. Эй Ходай, булган жанымнан, булган уйымнан Сине сӧйӧб, бар эшемдя дя Син кушканча кыларга миңа кыуат бир.

11. Эй Ходай, мине усал кешелярдян, шайтаннардан, няпеслярдян, ӓр-тӧрлӧ жарамаган эштян коткар.

12. Эй Ходай, Син Ӱзең дигянчя кыласың, Синең иркең мин жазыклыга да булсын, Син мянгегя данналыб торасың шул. Аминь.

## 8-нче иман, безнен Ходайыбыз Іисусъ Христоска.

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ, Алла Улы, Синең кадерле Таза Анаңнын, алдыңнан килеўче Чумылдырыучы пагямбяр Іоаннын, Алланы сӧйляўче Апостолларнын, арыулык белян жингян жакты азабланыучыларнын, кюнелляреңдя Алланы жӧрткян жараулы аталарыбызнын, бар ӓўлеяляреңнен дя телякляре какына мин мяндяңне ӓле миңа киля торган женнярнен ауларыннан котолдор. Эй Ходайым, Булдырыучым, Син жазыклынын ўлеўен телямейсең, ӓммя жазыгыннан кайтыб тере тороуын телейсең. Мин бичарага да жазыгымнан кайтырга булыш, харяб итеўче жыланнын сызгырыб жотоб, тере кӧйӧ тамукка тӧшӧрӧўеннян мине аралаб ал. Эй Ходайым, минем тынычлыгым, мин бичара ӧчӧн, минеке кюк тянгя кейенгянең, бичаралыктан мине жолоб чыгар. Минем мескен жаныма тынычлык бир. Минем кюнелемя начар эшлярне ташлаб, Син кушканны кылыу уйын бир. Шулай

итеб Син бирясе рахятлекне алсам ыйы, Сиңа ӧмӧтляндем, эй Ходай, мине сакла.

## 9-нчы иман, изгелекле Алла Анасына изге Петръ Студійскийныкы.

Аллабызнын Син иң кадерле Таза Анасына, булганнарнын Кыз Падшасына, мин мескен жыгылыб инялямен, мин туктаусыз жазыкланыб Синең Улың, минем Алламнын ачыуын китерямен, кюб табкыр тяӳбягя килсям дя, Алла алдында алдаучы буламын. Ӓлля инде Ходай мине бӧтӧнняй бетерер микян диб, калтраныб кна тяӳбя итямен. Шуннан суң ӳзем тагын ук шуны кыламын. Эй Алланы тыудырган оло Башкарыучыбыз, мыны белеб Сиңа инялямен, мине жарлыкасаң ыйы да, арыулык кыларга кюңелемне ныгайтсаң ыйы. Эй Башкарыучы Алланы тыудырыучы, Син белясең ич: мыннан ары мин ӳземнен жаман эшляремне кюрялмас буламын. Ӓммя бар кюңелем белян Алламнын законын сӧямен.

Эй̆ ин Таза оло Башкарыучы, тик белмей̆ем бит: нишляб кюрялмый̆ торган нястямне тагын сöямен, äммя арыулыкны кылмый̆ым. Эй̆ ин Таза Кыз, Син Ӱзен мина ӱз иркемне кыларга ирек бирмя, ул бит жараулы эш тöгöл. Äммя миндя Синен Улын, минем Алламнын ирке булсын, Ул мине коткарсын, акылга кертсен, Святый̆ Тыннын дяӱлятен бирсен, мыннан былай̆ мин шакшы эшлярне кылыудан туктасам ый̆ы да Синен Улыннын кушканын кылыб торсам ый̆ы. Анар äр-тöрлöчя даннау, кадерляу, тотоучылык тей̆ешле, Була башлаусыз Атасы белян, Тере итеӱче, изгелекле Святый̆ Тыны белян, äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

## 10-нчы иман, изгелекле Алла Анасына.

Эй̆ изге Падшанын изгелекле Анасы, Алланы тыудырган даннаулы ин кадерле Марія, Ӱз Улын безнен Аллабызнын изгелеген минем няпесле жаныма индереб, теляклярен бе-

лян мине жакшы эшляр кыларга ӧйрят. Мин калган гумер кӧнняремне жазыксыз ӱткязеб Синен арткылы жомак табсам ыйы, эй Алланы тыудырган Кыз, Син кадерле, даннаулы бер гня.

## 11-нче иман, саклаучы изге Пяриштягя.

Эй Христосъ Пяриштясе, мине саклаучы изге, бӧгӧн кылган жазыкларымны барын да минга кичер, усал дошманнын ăр-тӧрлӧчя алдауыннан мине коткар, бер жазык белян дя Алламнын катерен калдырмасам ыйы. Мин жазыклы усал мяндя ӧчӧн теляктя бул, Святый Ӧч ипостасьле Алланын да, Ходайым Іисусъ Христоснын Анасынын да, бютян ăулеяларнен дя изгелекляреня тейешле итеб кюрсят мине. Аминь.

## Кондакъ Алла Анасына.

Эй Алланы тыудырган Кыз, Син чиреӱ башлыгыдый безгя булышыб, дошманнары-

бызны жиндереб безне кысанныктан коткарганга, без мяндяларен тау итеб Сине ололаб данныйбыз, карышысында бер дя тора алмаслык кыуатын белян ӓр-тӧрлӧ бялядян безне коткар, без дя Синга былай ӑйтейек: эй кадерле Арыу Кыз, сӧйӧн.

Эй Алла Христоснын Анасы, жалан Таза кӧйӧ тороучы Изге Кыз, телягебезне Ӱз Улын Аллабыз алдына китер, Синен какына жаннарыбызны коткарсын ыйы.

Бар ӧмӧтӧмнӧ Синга саламын, эй Алла Анасы, мине Ӱзен жабыб сакла.

Эй Алланы тыудырган Кыз, мин Синен булышыуынгны, Синен жаклауынгны кирякссеня торган жазыклы мяндягнян жӧзӧнгнӧ борма, минем жаным Синга ӧмӧтлянде, мине жарлыка.

## Изге атабыз оло Іоанникійнен иманы.

Минем ышанганым Ата, минем сыйынга-

ным Ул, мине жабыучы Святый Тын, эй Святый Öчлö, шöкöр Синга.

Чыннаб дöрöс тейешле, эй Алланы тыудырган Кыз, Сине кадерляргя, Син мянгегя кадерле, шиксез Таза, Син безнен Аллабызнын Анасы, Херувимнярдян дя кадерле, Серафимнярдян дя данны, Кыз кöйö Сюз Алланы тыудырган чын Алла Анасы, Сине ололойбыз.

Шöкöр Атага, Улга, Святый Тынга, äле дя, äр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Эй Ходай, жарлыка. (*3 рят*)

Эй Ходайым Іисусъ Христосъ Алла Улы, Синен кадерле Таза Ананнын да, кюнелляренде Алланы жöрткян арыу тормошло аталарыбызнын, бар äÿлеяляренгнен дя телякляре какына мин жазыклыны да коткара кюр. Аминь.

## Изге атабыз Іоаннъ Дамаскінның иманы, мыны жатасы урнынны кулын белян кюрсятеб укы.

Эй Коткарыучы, Кеше сөйөүче, бу жатыр урын минга әлля инде гроб та булыр микян, әлля минем мескен жанымны тагын көн жактысы белян жактыртырсын. Мына минем алдымда гроб жата. Мына минем карышымда үлем тора. Эй Ходай, Синен хокөмөннян дя, мянге азабтан да куркамын, усаллык кылыудан тукталмыйым. Син Ходай Алламнын катерен туктаусыз калдырамын. Синен кадерле Ананнын да, Кюктяге бар чиреүлярнен дя, мине саклаучы Пяриштямнен дя катерен калдырамын. Эй Ходай, Синен кеше сөйөүлөгөнгя тейешле төгөл икянемне, әммя әр-төрлө айыблауга, азабка тейешле икянемне белямен. Эй Ходай, алай булса да, телясям дя, телямясям дя, мине Үзен коткара кюр. Син жараулыны коткарсан алай ук зур изгелек төгөл, жя чистаны жарлыкасан ис китярлек төгөл, андыйлар Синен изгелегенгя тейешле шул, әммя

мин жазыклыга Ӱзенгнен изгелегенгне кюрсят. Шуныҥ белян Ӱзенгнен кеше сөйөӱлөгенгне ангнат, минем усаллыгым Синеҥ ӓйтеб житкезялмяслек изгелегенгне, озак тюзеӱенгне алыб узмасын ыйы. Ӱзеҥ телягянчя эшляренгне булдыр мин мяндяня.

## Ӱрнына жатыр алдыннан быларны ӱкы.

Эй Алла Христосъ, кюзляремя жактыны кюрсят, жоклаганда ӱлмясям эйе, дошманым аны жиндем диб кыуанмасын ыйы.

Шөкөр Атага, Улга, Святый Тынга.

Эй Алла, Син минем жанымны саклаучы бул, мин кюб тозаклар арасында жөрөймен, алардан мине коткар. Эй Кеше сөйөӱче, изгелекле, мине сакла.

Ӓле дя, ӓр чакта да, гумердян гумергя. Аминь.

Алланын Арыу пяриштялярдян дя иҥ ка-

дерле Анасын кюҥел белян дя, тел белян дя туктаусыз даннйык. Ул Алланы тыудырган диб, чыннаб Ӱз эчендя Алланы тяннядереб Тыудырган шул, безнен жаннарыбыз ӧчӧн дя туктаусыз инялеб торадыр.

*Аннары ӱзеҥнен качыҥны ӱб, жата торган урныҥа башыҥнан аягыҥа чаклы кач кыл, шулай тӧрлӧ жакка да кач кыл, шул чакта тере итеӱче кадерле Качка шушы иманны укы:*

**А**лла торсон, Анын дошманнары таралышыб бетсенняр, Аны кюрялмый торганнар Анын жӧзӧннян качсыннар: тӧтӧн таркалыб беткян шикелле таркалыб бетсенняр: утта балауыз эрегян шикелле. Алланы сӧйӧӱчелярдян ӱзляреня Кач билгесе кылыб, кыуанышыб, эй Ходайнын Терелек биря торган иҥ кадерле Качы, сӧйӧн, Сиҥа кадакланган Ходайыбыз Іисусъ Христоснын кыуаты белян Син женнярне кыуасын. Ул тамукка тӧшӧб шайтаннын кӧчӧн бетереб, Син ка-

дерле Качны безгя ӑр-бер дошманны кыуарга биргян диб ӑйтеўчелярдян женняр качсыннар. Эй̆ Ходай̆нын Терелек биря торган иҥ кадерле Качы, Алланы тыудырган Башкарыучы Кыз белян, бар изгеляр белян бергя миҥа гумергя булышыб тор. Аминь.

*Шулай̆ кач кылганда былай̆ кыскача итеб тя ӑй̆тергя жарый̆.*

Эй̆ Ходай̆, Терелек биря торган кадерле Качыҥнын кыуатын ӑй̆лянямдя тотоб, мине ӑр-тӧрлӧ жаманнан сакла.

Аннары калдык сорау кӧнӧн исеҥя тӧшӧрӧб, Алла каршысына килеб жауаб бирясеҥне уй̆лаб, ўзеҥя кач кылыб, иман белян жоклаб кит.

## Иман.

Эй̆ Алла, иректян, ирексездян, жя сюз белян, жя эш белян, жя уй̆ белян, белеб, жя белмей̆, жя кӧндӧз, жя тӧння, уй̆ыбыз, сагышыбыз белян кылган жазыкларыбызны ташла,

кичер, бетер, барын да кичер безгя, Син Кеше сөйөүче, изгелекле.

## Иман.

Эй Кеше сөйөүче Ходай! безне кюрялмый тороучыларга, рянжетеүчеляргя кичер. Безгя жакшылык кылыучыларга Син дя жакшылык кыл. Карендяшляребезгя, жакыннарыбызга котолоу турысында телягянняре булдырыб арыу тормошны бир. Чирляб жаткаңнарны килеб төзят, дингездя жөрөүчелярне туры алыб бар, жулчыларга жулдаш бул. Башлыкларыбызга дошманнарын жиңеш. Безгя жакшылык, жя хызмят иткяннярнен жазыкларын кичер, без жараусызга үзляре өчөн теляк итяргя кушканнарны Үз оло изгелегеңнян жарлыка. Эй Ходай, элеке үлгян аталарыбызны, карендяшляребезне исеңя ал, аларны Үз жактын жактыра торган урынга кертеб тынычландыр. Эй Ходай, тотконга алынган карендяшляребезне исеңя ал, аларны әр-төрлө

тыгызлыктан коткар. Эй̆ Ходай̆, Синең арыу чиркяӱляреңя пай̆далы эш кылыучыларны исеңя ал, аларнын котолоуын телягянняреn булдырыб мянге тормошны бир. Эй̆ Ходай̆, без жазыклы, жараулы тӧгӧл мяндяляреңне дя исеңя ал, Ӱзеңне белеӱлек белян акылыбызны жактырылдыр, бой̆орокларыңнын жулына безне керт, Алланы тыудырган иң Таза Изге Кыз Маріянын, булган ӓӱлеяляреңнен телякляре какына. Син даннаулы гумердян гумергя. Аминь.

## Бар кӧннярдя дя кылган жазыкларны ӓй̆теб тяӱбя итеӱ иманы.

Эй̆ мине Булдырыучы Ходай̆ Аллам, Ӱзең Бер иң Святый̆ Ӧчлӧ диб без данный̆ торган, табына торган, Ата, Ул, Святый̆ Тын, мин ӱз гумеремнен бар кӧннярендя дя кылган жазыкларымны ӓй̆теб Сиңа тяӱбя итямен. Ӓр-бер сагяття, хазерге багытта да, узган кӧннӧ дя, узган тӧннӧ дя жазыкландым. Мин эшем бе-

лян, сюзем белян, уйым белян, артык ашау белян, эчкелек белян, жяшертен ашау белян, буш сюзляр белян, жукка моңайыу белян, жалкаулык белян, карышы ӓйтеу белян, тыңнаусызлык белян, ӓлякляӱ белян, кеше тикшереӱ белян, саксызлыгым белян, ӱземне гня сӧйӧӱ белян, кюб ӓйбер жыйыу белян, урлау белян, дӧрӧс сӧйляшмягянем белян, шакшыланыб жӧрӧӱем белян, кӧнняшеӱ белян, кеше тормошона кӧнчӧлӧк итеӱ белян, жарсыуым белян, усаллыкны истя тотоуым белян, кюремсезлек белян, малга биренеӱлек белян, аннары бар саннарымнын тойоноулары белян, кюз кюреӱем белян, колагым эшетеӱлек белян, ис тойоуым белян, ашамнык тяме тойоуым белян, кармалаб карауым белян, тагын да бютян тӧрлӧ жан жазыклары белян дя, тян жазыклары белян дя Син Алламнын катерен калдырдым, жакыныма да дӧрӧссӧзлӧк кылдым. Шушылар ӧчӧн ӱкенеб, ӱземне айыблаб Син Аллам карышысына китерямен, тяӱбя итяргя минга да ирек бар диб белямен. Эй Хо-

дай Аллам, кюз жяшем белян жыуашланыб Синнян телеймен: Син Ӱзең гня минга булыш, шушы узган багытта кылган жазыкларымны Ӱзеңнен изге кюнеллегең какына минга кичер, шушы Синең карышында айткянняремнен барысыннан да мине иркенгя чыгар, Син изге,Кеше сойоӱче шул.

## Жокога жатыр алдыннан шушы иманны айт:

Эй Ходай, тынымны Синең кулыңа табшырамын, Син мине жарлыка, Син мине бахилля, жаныма мянге тере тороулык бир. Аминь.

*Иртянге, кичке иманнар*
*(кряшенча)*

Верстка, дизайн:
Гришин Алексей Евгеньевич

www.missiakryashen.ru

*За помощь в издании выражаем благодарность*
*Мухину Николаю Алексеевичу*